**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 11 июнендәге 2445 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Идел буе районы Мирный торак массивында**
**ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитутның характеристикасы:

- йогынты ясала торган мәйдан – 231 кв.м;

- аңа карата хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры 16:50:171901:1;

- урнашу урыны: Казан шәһәре, Идел буе районы, Мирный торак массивы;

- билгеләү максаты: җирле әһәмияттәге ТП-29 бүлү подстанциясенең электр челтәре хуҗалыгы объектын урнаштыру;

- билгеләү вакыты: 49 ел;

1.2. гариза бирүче: «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»гы федераль законның 3.6 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының сак зоналарын билгеләү тәртибе һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым шартлары турында»гы карары (2018 елның 21 декабрендәге редакциядә), Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының Генераль планы, җирле әһәмияттәге РП-29 бүлү подстанциясенә милек хокукы теркәлгән (2001 елның 26 декабрендәге 16-50.3-23.2001-1281.4)

2. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендәге чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр

һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

3. Әлеге карарның 1 һәм 2 номерлы кушымталарында күрсәтелгән җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яисә сизелерлек кыенлашачак вакыт әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут вакытына туры килә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.


6. «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенә әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлеген, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яисә агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктларында каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң, өч айдан да соңга калмыйча, аннан рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерүне тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

1 номерлы кушымта
Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 11 июнендәге
2445 номерлы карары белән
расланды

**16:50:171901:1 кадастр номерлы җир кишәрлегенең бер өлешенә ачык сервитутның тәэсир итү өлкәсе чикләре**




Масштаб 1:250
Координаталар системасы: МСК-16

| Шартлы билгеләр: | |
|---|---|
| 1 | яңа ясалган характерлы нокта |

| | |
|---|---|
| (green line) | билгеләнә торган сервитут чиге |
| (dark line) | булган җир кишәрлекләренең чиге |
| (dashed line) | территорияләрдән файдалануның махсус шартлары |
| (red line) | кызыл линияләр (гамәлдәге) |
| (yellow rectangle) | капиталь төзелеш объектлары (мәйданлы) |
| 16:50:171901 | кадастр кварталы |
| 16:50:171901:1 | үзенә карата хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |